| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СУГУШЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«СУГЫШЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 2022 елның 19 декабре | №27 |

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2014 елның 7 июлендәге «Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип табуның өстәмә нигезләре турында» 12 номерлы карарына (06.07.2017г. №14, 19.09.2022г. №19 үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлыавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлыавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2014 елның 7 июлендәге «Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә еметсез дип табуның өстәмә нигезләре турында» 2 номерлы карарына (06.07.2017г. №14, 19.09.2022г. №19үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Атамасында «җирле салымнар буенча недоимка, әлеге салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләтүгә өметсез дип» сүзләрен «җирле салымнар суммалары өлешендә бурыч түләтүгә еметсез дип» (2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә) сүзләренә алмаштырырга;

беренче абзацның 1 пунктында «җирле салымнар, җыемнар һәм бу салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар түләтүгә һәм исәптән төшерүгә өметсезлек» сүзләрен «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләттерүгә өметсез» (2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә) сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктны 11,12, 13, 14, 15 абзацлар белән тулыландырырга:

- җирле салымнар буенча 3 елдан артык бурыч барлыкка килү датасы белән түләтеп булмый торган акт булганда;

- җирле салымнар буенча 2006 елның 1 гыйнварына кадәр недоимка яисә бурыч булган очракта;

- физик затларның җир салымы һәм балалар йортларында һәм ятимнәр учреждениеләрендә тәрбияләнүче, ата-аналары ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән балигъ булмаганнарның физик затлары мөлкәтенә салым буенча;

- ЕГРЮЛда мәгълүмат булмаган юридик затларның җирле салымнары буенча;

- недоимкага исәпләнгән юридик затларның пенялар буенча бурычлары булган җирле салымнар буенча, аны түләтү срогы тәмамланганнан соң, алар исәпләгән недоимкасы булмаганда

недоимкага исәпләнгән юридик затларда пенялар буенча бурыч булган очракта җирле салымнар буенча, аны түләтү срогы тәмамланганнан соң, алар исәпләнгән недоимка булмаганда.

2. Әлеге карарны ТР, Лениногорск районы, Сугышлы авыл җирлеге, Сугышлы авылы, Үзәк урам, 27 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (https://leninogorsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Сугышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы, Совет рәисе А.П. Зыятдинова